КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

2018 ел, 14 апрель г.Казань № 245

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 май, 340 нчы; 2009 ел, 2 февраль, 56 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1156 нчы; 2011 ел, 4 ноябрь, 918 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 696 нчы; 2013 ел, 16 декабрь, 995 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 52 нче; 2015 ел, 26 февраль, 116 нчы, 2016 ел, 19 май, 323 нче; 2016 ел, 3 сентябрь, 613 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән үзара бәйләнештә була:

түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01 <*>);

Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләүне тәэмин итү (01.05.01.01 <*>);

инвестиция эшчәнлеген дәүләт җайга салуы (01.10 <*>);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11 <*>);

хәйрия эшчәнлеге өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.17 <*>);

Татарстан Республикасының ведомство дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2 <*>);

билгеләнгән тәртиптә хезмәт белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән (01.13 <*>);

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән (01.15.02 <*>);

гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән (02.01 <*>);

түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норма чыгару эшчәнлеген координацияләү (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тикшерүдә тоту) (02.04.01 <*>);

республика башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03);

архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән (01.15.03 <*>);

социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг буенча комитеты белән (01.15.01.1 <*>).»;

5.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаны тулыландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитларын җәлеп итү юлы белән Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасының дәүләт эчке алынмаларын гамәлгә ашыру хокукы бирелгән очракларда Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаны тулыландыру өчен бюджет кредиты бирү турында шартнамә шартларын тиешенчә үтәүне тәэмин итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин